

Игенченен унганлыгы кырларыннан беленә. Ә савучыныкы? Чиста сыердан, сауган сотеннән генәме? Юк, эш кvрсәткечләреннән генә дә тvгел, нәтижәләреннән беленә. Атюрьево районы Усть-Рахмановка авылында 1953нче елны колхозчы гаиләсендә Мершидә Абдулхай кызы Байчурина туа. Яшьли әтисез калып vсә: Абдулхай абзи бик иртә бакыйлыкка кvчә. Гаилә башысыз гомер итvләр жинел булмый. Бертуган кызларын, Мершидә белән Адиләне аякка бастыру очен, әниләре Фәридә Хасян кызы икенче тапкыр Фатих абыйга кияvгә чыга һәм яна әти кызларга чын мәгънәсендә Әти була. Ике кызны бик тә vз итеп тәрбияли.      Авыл кешесенен балачагы бертор-лерәк vтә. Эш белән бергә. Мершидә Абдулхай кызы туган авылы Усть-Рахмановка мәктәбен тәмамлап, әнисе Мершидә апа белән сыерлар саварга эшкә урнаша. Беркемгә дә сер тvгел, ферма эше – жинел хезмәт тvгел. Аяктан резин итек, кулдан чиләк белән сәнәк тошми 90нчы елларга кадәр сыер савучыларынын. Әмма халык тырыша. Шул исәптән, сыер савучылар да. Житез, булдыклы кыз тиз арада кvрсәткән унышлары белән беренчеләр рәтенә чыга һәм озак еллар «Коммунар» колхозынын алдынгы сыер савучысы булып, фотосы Мактау такталарында эленеп тора. Мәктәп белеме белән генә ризалашып калмый Мершидә Абдулхай кызы, профессия vзләштерә. Зоотехник дипломы алгач, таналар группасына кvчерәләр аны, чонки беренче бозаулый торган сыерларны савучыларга зоотехния олкәсендә белемле кеше булырга кирәк. Ул группасындагы таналарынын һәрберсенен холкын белеп эш иткән. Плэмәле сыерларны сайлап алып бозаулаткан, хәлсез туган бозауларын сотлебикәләр янында тиешле вакытка кадәр-ныгыганчы тотып vстергән. Әйтеп китәргә кирәк, гаиләле сыер савучыларнын иртән балаларын мәктәпкә озату, ой эшләре белән бергә, сойләп бетермәслек авыр хезмәтләре була. Бу елларда сыерларнын кvбесен кулда сауганнар һәм сотле флягаларны кvтәрергә дә туры килгән, капчыктыгы фуражны да осләрендә ташып малкайларны ашатканнар. «Ашату, саву һәм карау технологиясен гел контрольдә тотсан, сыерлар сотне мул бирә. Бары тик, яхшы карасан һәм тәмле ашатсан гына сот кvләме арта иде. Бозаулар да тыпырдап торды. Вакыт vтv белән заманалар vзгәрде, сыер саву технологиясе башкарды, шартлар да яна. Бvген аппаратлар белән савып, трубалардан сот тиешле урынга ага», - ди яшьлеген сагынган Мершидә Абдулхай кызы Байчурина. Әмма Мершидә апа ул замандагы эштән сынмый да, сыгылмый да - хезмәт алдынгысы була. Колхозларынын сонгы коннәренә кадәр ул сот фермасы рәисе (МТФ заведующие) булып эшли һәм сот фермасы очен жаваплылык тулысынча анын остендә була. Тырыш хезмәте нәтижәләре буларак, анын кvпторле грамоталары бар: районнарынын, республикабызнын, Россиянын. Алар арасында «Знак Почета» ордены да бар. Бу орденны анын сот саву буенча нәкъ югары

кvрсәткечләргә ирешкән очен тапшырыла. Гаиләсе, ике бала анасы булуга карамастан, озак еллар җәмәгать эше белән дә шогыльләнә ул - Атюрьево районы райсовет депутаты да була. Авыл мәсьәләләрен район кvләменә кvтәреп хәл итә торган булган. Бvген ул хезмәт ветераны. Мершидә Абдулхай кызы Байчурина, лаеклы ялга чыккач, тормыш иптәше Ринат белән, уллары Руслан һәм Рушаннын балаларын, оныкларын тәрбияләргә булышалар. Балалары Мәскәvдә яшәсәләр дә, еш йореп торалар әти-әниләренә, ә оныклары җәй коне Усть-Рахмановкада милли рухка чумып ял итәләр. Мершидә апа унган хуҗабикә дә. Ой ишекләрен ачуга, анын тәмле бәлеш һәм пәрәмәч исләре борын-нны котыклый, авызга сулар килеп китә. Унган кулинарыбыз рецептларын да сораганнарга бирә. Алар оенә килгән һәрбер кешене шат йоз белән каршы алалар; татарларга хас булган кунакчыллык буенча, чәй эчмичә җибәрмиләр.

**Наилә Насырова**